ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2025 Олы Кайбыч ав. № 435

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 16 ноябрендәге 442 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Су кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 16 ноябрендәге 442 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Коену зоналарына түбәндәге таләпләр куела:

- су объекты су сыйфатының һәм территориянең санитария торышының ГОСТ 17.1.5.02-80 стандарты таләпләренә туры килүе;

- суга җайлы һәм куркынычсыз якын килүләр булу яисә аларны оештыру мөмкинлеге;

- рекреация зонасына керү юллары булу;

- төпнең куркынычсыз рельефы (су үсемлекләренең, очлы ташларның, чокырларның булмавы һ.б.);

- уңайлы гидравлик режим (су төпкелләре, 0,5 м/с көчле агымнар, су өсте тигезлегенең кискен тирбәлешләре булмау);

- уңайсыз һәм куркыныч процесслар (җир шуышу, убылу, ташкын лавина) мөмкинлекләре булмау.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлшен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Е.Г.Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров